**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БОЛЬШЕБИТАМАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422725, Республика Татарстан, Высокогорский район,
с. Большой Битаман, ул. Московская, 2В

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ БИТАМАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
422725, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Олы Битаман авылы, Мәскәү ур., 2В.

тел./факс 8(84365) 62-8-47, e-mail: Bbit.Vsg@tatar.ru

**КАРАР** **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**28 июнь 2024е.** **№ 13**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Олы Битаман авыл җирлеге башкарма комитетының 01.12.2019 елда кабул ителгән 24 номерлы «Бюджет өлкәсенең бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым оешма хезмәткәрләре, баш хисапчы һәм хисапчыларның, шулай ук Биектау муниципаль районы Олы Битаман авыл җирлеге Башкарма комитетының хәрби исәп хезмәткәрләренең хезмәт хакын түләүне оештыру шартлары турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 18.04.2024 елның 03-12/2677 номерлы «Шәһәр һәм авыл җирлекләре үзәкләштерелгән бухгалтерияләре җитәкчеләренә һәм белгечләренә хезмәт хакы түләү турында» хаты нигезендә һәм Биектау муниципаль районы Олы Битаман авыл җирлеге башкарма комитеты муниципаль берәмлеге учреждениеләре хезмәткәрләренә хезмәт хакы түләү системасын камилләштерү максатларында, Биектау муниципаль районы Олы Битаман авыл җирлеге башкарма комитеты

**КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:**

1. 2024 елның 1 июленнән «Бюджет өлкәсенең бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым оешма хезмәткәрләре, баш хисапчы һәм хисапчыларның, шулай ук Биектау муниципаль районы Олы Битаман авыл җирлеге Башкарма комитетының хәрби исәп хезмәткәрләренең хезмәт хакын түләүне оештыру шартлары турында» 2019 елның 01 декабрендәге 24 номерлы (30.09.2020 № 30, 13.12.2022 № 31) Биектау муниципаль районы Олы Битаман авыл җирлеге башкарма комитеты карары белән расланган үзәкләштерелгән бухгалтерия баш хисапчылары һәм хисапчыларның айлык хезмәт хакы күләмен арттырырга.

2. «Биектау муниципаль районы Олы Битаман авыл җирлегендә баш хисапчы һәм хисапчыларның (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфасына кертелгән вазыйфалардан тыш) хезмәт хакын түләүне оештыру һәм шартлары турында» нигезләмәнең 3 пунктында “Хисапчыларның вазифаи окладлары түбәндәгечә күләмдә билгеләнә” таблицасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| Вазифа | Халык саны түбәндәгечә булган муниципаль берәмлекләрнең башкарма комитетлары |
|---|---|
| | 3,5 меңгә кадәр кеше |

| | |
|---|---|
| Баш хисапчы (1 ст.) | 23 700 |

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адрес буенча һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы» на: http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карар 2024 елның 1 июленнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Авыл җирлеге башлыгы урынбасары: Г.Н.Ибраһимова